Мәктәп хәбәрчесе

№8 (№49) октябрь 2023 ел

Түбән Майна урта мәктәбе гәзите

Тел. 8 (84344) 4-38-46 sch1644maina@mail.ru

/Мөхәррир минбәре/

Балабыз мөстәкыйльме?

Һәр әти–әни үз баласының уңышлы булуын, укуда да, тормышта үз урынын табуын тели. Бу дөрес тә. Киләчәктә уңыш китерә торган мөстәкыйльлек тәрбияләүнең алтын уртасын табу гына кыен. Бүгенге шартлар да бигрәк тә. Чөнки балаларыбыз әти-әни тарафыннан ныклап күзәтелә, һәр эше җиңеләйтелә. Ә мөстәкыйльлекне кайчан тәрбияләргә?

Мөстәкыйльлек – ул кемнең дә булса ярдәменнән башка үзең генә эш итә белү һәм үйлаган эшләреңне тормышка ашыру, һәр эштә үз фикереңне күрсәтү дигән сүз. Мәктәпкәчә яшьтәге балаларга, башлангыч сыйныфларга яшь үзенчәлекләренә карап, үзләре җавап бирә алырлык дәрәҗәдә мөстәкыйльлек бирүне хупларга кирәк. Нәкъ менә шул яшьтәге балаларда җаваплылык тәрбияләү шәхес формалаштыру процессында иң әһәмиятле урынны алып тора. Бала һәр эштә үз сүзеңдә тора белсә, кушылган эшне үтәргә тырышса, төрле юк-барга алданмаса- киләчәге ышанычлы булачагына шик калмас иде. Балага иң элек үз коллективында, ә киләчәктә җәмгыятьтә, эшендә танылырга һәм уңыш казанырга мөстәкыйльлек сыйфаты ярдәм итәр иде.

Бүгенге укытучылар менә нәкъ шушы сыйфатларны тәрбияләүдә кыенлыкка очрыйлар диясем килә. Төрле психологларны да тыңлаганнан соң да, күп очракта без, әти-әниләр дә, укытучылар да үзебезнең хаталарыбызны да танырга мәҗбүр булабыз. Балага һәр эшендә артык ярдәм итү, һәр минутын күзәтү, аны авырлыклардан саклауда да, бәлки, ялгышабыздыр. Чөнки гади генә нәрсәләр дә балабызда мөстәкыйльлек тәрбияләр иде. Аяк киемнәрен дөрес кую, шнурлы киемен бәйли белү дә – аңа моторика ягыннан файда бирер иде. Ә без, әниләр, аяк киемененең җиңел киелә торганын эзлибез.

Мәктәптә киену-чишену бүлмәсендә тәртип урнаштырыр өчен берничә ел "көрәш" алып барабыз. Анда укучыларның ташлап калдырган киемнәре әллә никадәр. Күп тапкырлар балаларга ул киемнәрне күрсәтсәк тә, танып алучы булганы юк. Югыйсә, мәктәптә балалар саны да күп түгел. Бу хәл – җавапсызлыкның бер төре дип уйлыйбыз. Әти-әни ел башында алып биргән кыйммәтле киемнәргә шундый караш булганына җан авазы бу.

Икенче мәсьәлә булып, баланың дәрескә әзерләнми килүе, китап-дәфтәрен онытуы, иртән соңга калулары – болар да мөстәкыйль булмау, җавапсызлыкның бер төре. Мондый тискәре күренешләрнең гадәткә әверелүе яхшыга түгел. Чөнки еш кабатланган гадәт кешенең холкына күчә торган була. Бала гаиләдә, әти-әни карамагында яшәгәндә начар гадәтнең йогынтысы артык сизелмәскә дә мөмкин. Тик мөстәкыйль тормыш юлына баскач тискәре гадәтләр үзен сиздерәчәк.

Һәр кеше иҗат итәргә сәләтле булып туа. Ләкин шул сәләтне ачарга, ирекккә чыгарырга, аңа үсү өчен тиешле шартлар тудырырга кирәк. Укучыларның иҗади мөмкинлекләрен ачу – иң төп, мөгаен, иң авыр мәсьәләләрнең берседер. Иҗат-ул мөстәкыйльлек, бәйсезлек, үзенчәлекле фикерләүне таләп итә. Безнең максат – укучыларда шушы сыйфатларны бергәләп үстерү. Бөек галимебез Р.Фәхреддин әйткәнчә, "һәрбер кеше үз кулыннан килгән кадәр эш эшләргә, байлык вә һөнәр, һәм дә сәнгать өлкәләрендә милләтнең күтәрелүенә ярдәм кылырга тиеш. Халкының үткәнен, тарихын, сәнгатен өйрәнгән, хезмәт сөйгән, матурлыкны күрә белгән, үзара дус һәм тату мөнәсәбәттә тәрбияләнгән балаларның киләчәге өметле".

Фәнүзә Гафиятуллина, баш мөхәррир

5 нче октябрь – Укытучылар көне

Хөрмәтле укытучылар!

Сезне һөнәри бәйрәмегез белән котлыйбыз. Сез – безнең иң кадерлеләребез, үрнәк алырлык кешеләребез, туры юл күрсәтүчеләребез. Сез биргән белемнәр, сезнең үгетнәсыйхәтегез безгә тормышта дөрес юлдан тайпылмыйча, гел алга барырга ярдәм итә. Бүгенге заманда укучы белән бергә атлап, заман таләпләренә җавап бирә алырлык ихтыяр көче, сабырлык, иҗади үрләрне яуларга үҗәтлек, тирән белем телибез!

20 нче октябрь – Пешекчеләр көне

Зиһенебез белән бергә тамагыбызны кайгыртучы пешекче апаларыбызны да һөнәри бәйрәмнәре белән котлыйбыз. Сез пешергән ризыклар белән һәр көнне бәйрәмчә тукланабыз. Ашханә сезнең ягымлы йөзегез белән һәрвакыт җылы һәм балкып тора. Сезгә ныклы сәламәтлек, гаилә иминлеге, озын гомер телибез!

Октябрь ае бәйрәмнәре /Безнең бәйрәмнәр/

Октябрь ае бәйрәмнәргә бай. Иң элек 1 нче октябрьдә өлкәннәребезне ихтирам итеп, аларны котлыйбыз. 5 нче октябрьдә – Укытучылар көне. Бу көнне безнең укучылар укытучы апа-абыйларыбызны ял иттерделәр. Өлкән сыйныф укучылары шушы көнге расписание белән, укыту эшләрен оештырып, алып бардылар. Морадимов Илсур –директор, Шичкина Карина – завуч, Нурматов Муса – математика укытучысы, Гафиятуллин Самат – тарих, Нурматова Зәйнәп – рус телен укыттылар.

Мәдинә Әхсәнова, VI сыйныф укучысы

Сөмбеләне кем белә?

Беренче чирек тәмамланыр алдыннан мәктәбебездә елдагыча Уңыш бәйрәме үткәрелде. Без быел башлангыч сыйныф укучыларының "Сөмбелә" бәйрәменә кунакка кердек. Бәйрәмдәге һәрбер бала яшелчә булып киенгән иде. Бәйрәм кунагы булып Уңыш әби килде. Ул балаларның җырларын, шигырләрен игътибар белән тыңлады. Укучыларның зирәклеген тикшереп, җиләк-җимешләр турында табышмаклар әйтте. Соңыннан кәрзиненә салып килгән кызыл алмаларын балаларга өләште.

Уңыш әби артыннан Сөмбелә килде. Ул балаларга төрле үеннар уйнатты. Бәйрәм бик күңелле, эчтәлекле узды. Килгән кунаклар балаларының ясаган рәсемнәренә сокландылар. Әлбәттә инде, көзге муллык өстәле һәр тамашачының игътибарын үзенә җәлеп итте. Шулай ук залда көз темасына ясалган фотозона бар иде. Монда барыбыз да сыйныфлар, әниләр белән фотога төштек. Ахырдан укучылар әниләре белән тәмле итеп мулдан әзерләнгән өстәл артына җыелдылар.

Менә шулай кызык, мавыктыргыч һәм тәмле итеп узды башлангыч сыйныфларның "Сөмбелә"бәйрәме.

Ләйсән Закирова, VI сыйныф укучысы

Бездә булды КВН – бик тә күңелле уен

21 нче октябрь көнне авыл клубында өлкән һәм урта сыйныфларның ел да үткәрелә торган КВННары узды. КВН ны без һәрвакыт көтеп алабыз. Бәйрәмгә ике атна кала бик тырышып җиңүгә әзерләндек. Мондый вакытта укучыларның мөстәкыйль була алулары, тырышлыклары чынлап торып сынала.

Ике командага бүленгән укучылар үзләренә "Яшен" һәм "Дуслык" исемнәре алып ярышты. Таныштырулар да үзенчәлекле, сюжетлы итеп төзелгән иде. Җырлары да да матур итеп яңгырады. Мода күрсәтү барыбызны да таң калдырды. Чөнки гади генә материаллардан киемнәр тегеп кигәннәр иде. Театр сәнгате дә укучыларыбызны читләтеп узмаган. Менә дигән итеп сәхнәне үзләренә буйсындырдылар.

Командалар ярышларга әзерләнгән арада V һәм VI сыйныф укучылары тамашачыны ял иттерде. Бу укучылар да сәхнәдә үзләрен ышанычлы тоттылар. Авыл темасына багышланган җырлар, шигырьләр бик матур яңгырады. Кечкенә миниатюралар да тормышчан итеп күрсәтелде.

Ахырдан жюри җиңүчеләрне билгеләде. 51,5 бал белән "Яшен"командасы җиңү яулады. "Дуслык"командасы 1 бал белән генә артка калды. Ни генә булса да, командалар ахырдан бергәләп башкарган "Дус" җыры девизлары булып яңгырады. Һәрвакыт дус булып, ярдәмләшеп, сәхнәдәге кебек тырышып, уңышлы яшәгез.

Кәүсәр Насыйрова, VI сыйныф укучысы

/Безнең спорт/

Каникулның беренче көне – 28 нче октябрдә Әлки районында Айрат Хайруллин истәлегенә багышланган билбау көрәше буенча республика турниры узды. Безнең укучыларыбыз да читтә калмады һәм үз авырлыкларында җиңүләр яулап кайттылар: **Җамалетдинов Зөлфәт** белән **Хәбибрахманов Абдулла** – II урын, **Сәгъдиев Рәмзис** – III урын. Афәрин, егетләр. Киләчәктә дә сәламәт булып, уңышларның зурысына ирешегез!

Газетаны гамәлгә куючы – Түбән Майна урта мәктәбе
Мөхәррир – Фәнүзә Гафиятуллина
Редколлегия әгъзалары: Зәйнәп Нурматова, Самат Гафиятуллин, Кәүсәр Насыйрова, Ләйсән Закирова, Мәдинә Әхсәнова, Камил Төхвәтуллин

/Рәсми хәбәрләр/

27 нче октябрь көнне 2023-2024 нче уку елының беренче чиреге тәмамланды. 8 атна уку дәверендә мәктәпнең 41 укучысының 33енә чирек билгеләре чыгарылды. Белем сыйфаты 45,5 % тәшкил итте. Отличниклар: II сыйныфтан **Гафиятуллина Руфинә**, III сыйныфтан **Закиров Инсаф** белән **Камалов Илнур**, IV сыйныфтан **Нурматова Асия**, VI сыйныфтан **Закирова Ләйсән**, VII сыйныфтан **Гафиятуллин Фаил**.

13нче октябрь көнне мәктәп белән Бөтендөнья "Татарча диктант" белем тикшерү акциясендә катнаштык. Мәктәп укытучылары, өлкән сыйныф укучылары үз туган телләрендә диктант язып белемнәрен тикшерделәр.

Илдар Сафиуллин, уку-укыту эшләре буенча директор урынбасары

Республикакүләм конкурс нәтиҗәләре

/Мәктәп тормышы/

Сентябрь ае керү белән башлангыч һәм урта буын укучылары ел саен катнашып килә торган республикакүләм “Матур язу” иҗади конкурсына әзерлек башлана. Бу олимпиада укучыларны иҗади яктан да, белем ягыннан да сыный торган, берничә турдан торган чара. I тур эше булып, балаларга өй эшенә каллиграфик алфавитны зәвыклы итеп бизәп алып килергә кушылган иде. Безнең укучылар бу турда барысы да югары баллар алдылар. Олимпиаданың икенче туры белем тикшерү һәм язу күнекмәләрен сынау булды. Монда да укучыларыбыз сынатмады. Ахырдан барлык балларны санап, урыннар билгеләнде. Хәйруллин Мансур (I сыйныф), Гафиятуллина Руфинә (II сыйныф), Хафизов Илфат (II сыйныф), Нурматова Асия (IVсыйныф), Закирова Ләйсән (VI сыйныф) җиңүче исеменә лаек булдылар. Хәбибрахманова Асия (I сыйныф), Камалов Илнур (III сыйныф), Донсков Артур (IV сыйныф), Насыйрова Кәүсәр (VI сыйныф), Аксанова Мәдинә (VI сыйныф) призер исемен алдылар. Күргәнебезчә, катнашкан һәр укучыбыз урынлы булды, бу исә аларның һәм әзерләтүче остазларының хезмәт җимешләре.

7 нче октябрь көнне район үзәгендә республикакүләм математик олимпиада булып узды. Бу чарада мәктәбебезнең яшь математиклары көчләрен сынап карадылар һәм сынатмадылар. I сыйныф укучылары Хәйруллин Мансур һәм Хәбибрахманова Асия җиңүче грамоталары белән бүләкләнделәр. Шулай ук җиңүче исеменә III сыйныфтан Закиров Инсаф та лаек булды. Әйтергә кирәк, Инсаф әлеге олимпиада да ел саен катнашып, урыннар алып килә. Укучыларыбызны җиңүләре белән чын күңелдән котлыйбыз. Киләсе елга бу исемлек тагын да артыр дигән өметтә калабыз.

Гөлшат Закирова, башлангыч сыйныф укытучысы

/Безнең бәйрәмнәр/

Көзбикәдә кунакта

Безнең мәктәптә октябрь ае һәр елдагыча көзге бәйрәмнәр булән уза. Бу бәйрәмнәр яңа уңышка шатлану, көзге муллыкны булдыручыларның тырыш хезмәтен хөрмәтләү өчен кирәк. Ә балалар бакчасындагы кечкенә балаларга ипинең тормыш чыганагы икәненә, аны кадерләргә ничек аңлатырга? Безнең балалар әкияти тамашалар, уеннар, мультик, күзәтүләр һәм иҗади эшләр аша моңа бик шатланып өйрәнәләр.

27нче октябрь көнне балалар бакчасында "Көзбикәдә кунакта” дип исемләнгән уңыш бәйрәме узды. Бәйрәмне карарга әниләр һәм башлангыч сыйныф укучылары да кергән иде. Нәни балалар бу чарада алда өйрәнгән белемнәрен һәм сәләтләрен күрсәттеләр:

- көз көненә хас сыйфатларны өйрәнү;
- яшелчә һәм җиләк-җимешләрнең исемнәрен һәм аларның тәмнәрен аера белү;
- җыр һәм биюләр аша табигатькә карата җылы хисләр уяту;
- уеннар аша балаларның бер-берләренә карата дуслык тәрбияләү, кагыйдәләрне төгәл үтәргә өйрәтү.

Менә шундый бурычларны күздә тотып уздырылган бәйрәм балаларның да күңеленә хуш килгәндер. Чөнки алар барысы да бик шат күңелле һәм канәгать иделәр, һәр чарада актив булдылар. Бәйрәм ахырында балаларны көзге муллык хөрмәтенә әзерләнгән тәмле табын көтә иде.

Зәйнәп Нурматова, X сыйныф укучысы

/Котлыйбыз!/

Октябрь аенда дөньяга килгән дусарыбыз – III сыйныфтан **Закиров Инсафны**, VII сыйныфтан – **Хәбибрахманова Хәнифәне**, VIII сыйныфтан – **Нургалиева Ләйләне** туган көннәре белән котлап, ныклы сәламәтлек, укуларында уңышлар теләп калабыз!

Башлангыч сыйныф укытучысы **Камалова Сирин апаны** гомер бәйрәме белән котлап, саулык-сәламәтлек, эшендә уңышлар, гаилә иминлегә телибез!

/Күренекле шәхесләр/

Хәтерлим мин әле бүгенгедәй...

Ел саен октябрь санында мәктәбебездә озак еллар укучыларга белем һәм тәрбия биргән укытучыларыбызның тормыш юлыннан “өзек”китерергә тырышабыз. Бу юлы сүзебез хезмәт юлын башлангыч сыйныфларга белем һәм тәрбия бирүгә багышлаган Гафиятуллина Зөлфия апа Мөнип кызы турында булыр.

- Зөлфия апа, укытучы һөнәре нинди ул, сезнеңчә?

- Сабый чакны артта калдырып, тәүге тапкыр мәктәп бусагасын атлап кергәндә, колачын җәеп, хуш киләсең, диеп каршы алучы, еллар буе шатлык-борчуларны бүлешеп яшәп, олы тормыш юлына аяк басканда балаларга төпле һәм акыллы киңәшләрен бирүчедер диеп үйлыйм. Үзем шулай булырга тырыштым.

- Үзегезнең бала чагыгыз белән таныштырып үтсәгез иде?

- Мин күрше авыл – Иске Татар Әдәмсуында 1965 нче елда күп балалы гаиләдә бишенче бала булып туганмын. Балалар бакчасы, мәктәп, аннан Алабуга дәүләт педагогика институтында укыдым. Башлангыч сыйныфлар укытучысы булдым. Укыганда да авыр булды. Тик яшь чак үзенекен эшли. Авырлыктан курыкмадык, әти-әниләргә борчу китермичә укырга тырыштык.

- Укытучы булу теләге ни рәвешле туды?

- Мин бу һөнәрне балачактан яраттым. Беренче укытучым Кәүсәрия апа мине гел мактап, үсендереп торды. Сыйныфыбызда иң өлгер укучы да мин идем. Шуннан ул гел миңа гел “үз урыныма кайтырсың инде” диеп, әйтеп торды. Аның юраганнары туры килгән, күрәсең.

- Сез диплом алуга ук эшкә авылга кайттыгызмы?

- Әйе, язмыш мине Түбән Майнага китерде. 1986 нчы елда Асия апа балалар бакчасына эшкә чакырды. Бер ел анда эшләгәннән соң, мәктәпкә чакырдылар. Мин 1980 нче елда туган балаларны – беренче укучыларымны кабул итеп алдым. Алар хәзер үзләре әти-әниләр инде. Авылда Гафиятуллин Фәнил абыегыз – минем беренче укучыларымнан.

- Ничә буын балалар чыгардыгыз, Зөлфия апа?

- Мин менә сез сорагач кына санадым. 15 буын – 15 тапкыр беренче сыйныфларны кабул иткәнмен. Барысы 37 ел хезмәт стажым санала.

- Сез бит балалар белән 1986 нчы елда башладым дидегез. Соңгы елларда хәзерге буыннарны да укыттыгыз. Төрле чор балалары арасында аерма бармы?

- Һәр заманның үзенә күрә авырлыгы да, җиңеллеге дә бар. Хезмәтемнең күп өлешендә балаларга аңлату өчен барлык күрсәтмәлелекне күлдан ясадык. Күңел җылысын да куша идек. Аннан инде компьютерны да үзләштердек. Заманча технологияне кулланырга да өйрәндек. Заманадан артта кала алмый укытучы. Балалар белән бергә атласаң гына, аларның теләкләрен тойсаң гына белемне биреп була.

- Әти-әниләр белән мөнәсәбәтләр ничек иде?

Аллага шөкер, бер-беребез белән аңлашып, ярдәмләшеп эшләдек. Укытучы киңәшен тотып, әниләр тырышты. Бердәм булып, бер юнәлештә эшләсәң генә нәтиҗә була. Мәсәлдәге кебек төрле кеше төрле якка тартса, авырлыклар җиңелми.

- Нинди киңәшләр бирер идегез укучыларга һәм үзегезнең эшне дәвам итүче укытучыларга?

- Бала һәр чорда да бала инде ул. Ә укытучыларга килгәндә, бу һөнәрнең иң төп сыйфаты – эшне яратып башкарудадыр дим. Эшне яратмасаң, бер урында гомер буе эшләп булмый. Эш ул күңел хәләте кебек. Балалар белән эшләгәндә бигрәк тә, алар синең карашыңны бик тиз тоемлый.

- Хәзерге заманның төп проблемасын нидә күрәсез?

- Бүгенге көндә балалар тәрбияләүдәге иң зур мәсьәлә – матур итеп туган телдә сөйләшергә өйрәтүдер дип исәплим. Без туган телебезне балалар яратсын, яхшы белсен дип тырыштык. Алга таба да туган телдә сөйләшүче балалар тәрбияли алсак иде дип телим. Чөнки тел яшәсә генә халык яши. Ә телне сез генә саклый аласыз.

- Әңгәмәгез өчен зур рәхмәт, Зөлфия апа. Сезгә сау-сәламәт булып, укучыларыгыздан рәхмәт сүзләре генә ишетеп яшәү насыйп булсын.

Мин дә укытучым теләкләренә кушылам. Туган телебезгә тугрылыклы калып, милләт уллары, кызлары була алсак иде. Менә шундый көчле рухлы мөгаллимнәр үрнәгендә без, яшь буын, тәрбияләнәбез һәм милләт сагында торырга әзер кешеләр булырбыз дип ышанам.

Әңгәмәне Самат Гафиятуллин алып барды